ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 1-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 56-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), _____ түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 42 пункт өстәргә:

«42) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

б) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:

«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

2) 17 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 46 пункт өстәргә:

«46) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

Закон проекты «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

Шулай итеп, 2024 елның 2 августында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 22 июлендәге 213-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә керде.

Әлеге Федераль закон белән хуҗалык кенәгәләрендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу мәсьәләсе җирлекләрнең һәм шәһәр округларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелгән.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына шундый ук үзгәрешләр кертү каралган.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 15 һәм 17 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.